Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР
07.11.2022 ел — №7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылында гражданнар җыенын 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы, Кызыл Бакча авылы, Кызыл Бакча урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында 2022 елның 17 ноябрендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә

әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылында Кызыл Бакча торак пункты зиратына килү юлларын (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) төзекләндерү;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында балалар уен мәйданчыгын коймалау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән биш көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р. Ә. Каримов